ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОГДАШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

БОГДАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ НУРЛАТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

Рус
Богдашкинос
ы

БОЕРЫК

03.02.2020

№ 2

Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2020 ел, 29 гыйнвар, 61 номерлы карары нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Нурлат муниципаль районының Богдашкино авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта нигезендә 6124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм 2020 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2019 елның 23 апрелендәге 8 нче карары 2020 елның 1 февраленнән үз көчен югалкан дип санарга.

3. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының Богдашкино авыл җирлеге территориясендә мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Богдашкино авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Л. Михайлова

Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 3 февралендәге 2 номерлы карарына 1 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән ТР Нурлат муниципаль районы Богдашкино авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе.
*(православие йоласы)*

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны китереп бирү | 2340,33 |
| 3. Мәетне (җәсәдне) зиратка илтү | 944,51 |
| 4. Җирләү хезмәте (кабер казу һәм җирләү ) | 2840,02 |
| Барлыгы | 6124,86 |